КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 30 март г.Казань № 196

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 932 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләүдә булышлык күрсәтү һәм аларны үткәрүгә бәйле булган мәсьәләләрне хәл итү буенча эшче төркем составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 932 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләүдә булышлык күрсәтү һәм аларны үткәрүгә бәйле булган мәсьәләләрне хәл итү буенча эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан Г.Ю.Вафинны, А.А.Здуновны, Р.М.Ильясовны, Э.Н.Фәттаховны, М.З.Шакировны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасының икътисад министры Фәрид Солтан улы Габделганиевне;

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы – Татарстан Республикасының баш суд приставы Игорь Метиславович Безуевскийны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры Рафис Тимерхан улы Борһановны;

«Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе Әгъзам Самат улы Гобәйдуллинны (килешү буенча);

Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры Марат Наил улы Садыйковны;

Марат Дамир улы Шәрифуллин вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе башлыгы урынбасары – Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлеге – Татарстан Республикасы буенча Милли банкы идарәчесе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин